РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 10 2018 г. №754

Гражданнарны патриотик тәрбияләү буенча Координация советы оештыру турында

Халыкның гражданлык һәм патриотизм дәрәҗәсен күтәрү, патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү, аныц эчтәлеген яңарту һәм белем бирү учреждениеләренең патриотик тәрбияләү буенча көчләрен берләштерү максатыннан, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1.Ютазы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны патриотик тәрбияләү буенча Координация советы төзергә.

2. Ютазы муниципаль районының Координация советы турында Нигезләмәне расларга (№1 кушымта).

3. Ютазы муниципаль районы гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча Координация советы составын расларга (№2 кушымта).

4. Ютазы муниципаль районы гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча чаралар планын расларга (№3 кушымта) .

5. Әлеге Карарныц үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

А.А.Хисмәтуллин
2-81-97

Кушымта №1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
______________2017 ел № ______

Нигезләмә
Патриотик тәрбия буенча Координация советы оештыру турында

1. Гомуми нигезләмәләр
1.1. Муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче гражданнарга патриотик тәрбия бирү буенча Координация советы (алга таба - Координация советы) халыкның гражданлык һәм патриотизм үсеше, иҗтимагый оешмаларның җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеге, гражданлык-патриотик тәрбия программасын үтәү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында 2018-2021 елларга "Мин - Россия гражданины һәм патриоты» программасы һәм гражданнарны патриотик тәрбияләү планы үтәлешен оештыру һәм контрольдә тоту буенча тәкъдимнәр эшләү максатларында оештырылган ведомствоара консультатив-киңәшмә органы булып тора.
1.2. Координацион совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе закончалыгы, Ютазы муниципаль районының законнары һәм норматив актлары, муниципаль берәмлекнең норматив-хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.
2. Координацион советның төп бурычлары һәм эшчәнлек юнәлешләре.
2.1. Координацион советның төп бурычлары булып тора:
- патриотик тәрбияне үстерү һәм аны тормышка ашыруда өстенлекле юнәлешләр формалаштыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;
- гражданнарны патриотик тәрбияләү буенча чаралар планын эшләү һәм корректировкалау, план чараларының үтәлешен координацияләү һәм контрольдә тоту;
- халыкны патриотик рухта тәрбияләүнең актуаль проблемаларын хәл итүдә җирле үзидарә органнары, башкарма хакимият органнары һәм төрле юнәлештәге иҗтимагый берләшмәләр (милли, яшьләр, хокук саклау, дини һәм башкалар) эшчәнлеген координацияләү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- балаларны һәм яшьләрне патриотик агарту һәм тәрбияләү өлкәсендә эш тәҗрибәсен гомумиләштерү.
2.2. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Координация советы түбәндәгеләрне эшли:
- патриотик тәрбия мәсьәләләрен хәл итү буенча иҗтимагый берләшмәләрнең, белем бирү учреждениеләре, төрле оешмаларның эшен анализлый;

- гражданнарга патриотик һәм гражданлык тәрбиясе бирү өлкәсендә белем бирү учреждениеләре, иҗтимагый берләшмәләрнең эш тәҗрибәсен өйрәнә;
- гражданлык-патриотик тәрбия бирү кысаларында үткәрелә торган яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча чаралар оештыру һәм уздыруны координацияли;
- патриотик тәрбия бирү проблемалары буенча белешмә һәм мәгълүмати материаллар әзерли;
- гражданнарны патриотик тәрбияләү эшчәнлеген даими контрольдә тотуны һәм анализлауны оештыра, аларның эшчәнлеген камилләштерү һәм үстерү буенча тәкъдимнәр әзерли.

3. Координация советының эш тәртибе

3.1. Координация советы үз эшчәнлеген эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

3.2. Координация советының эш формасы булып утырыш тора. Координация советы утырышы кирәк булган вакытта уздырыла, әмма өч айга бер тапкырдан да ким түгел.

3.3. Координация советы утырышының көн тәртибе Координация советы рәисе тарафыннан Координацион совет карарлары, Координация советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә төзелә һәм Координация советы утырышында раслана.

3.4. Координация советы утырышы, әгәр анда Координация советы әгъзаларының исемлек составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы санала.

3.5. Координация советы утырышлары ачык булып тора.

3.6. Эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча эшне оештыру өчен Координация советы Координацион совет әгъзалары җитәкчелегендәге эшче төркемнәр төзергә хокуклы.

3.7. Координация Советы карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, Координация советы рәисе яисә аның рәистәше, утырышта рәислек итүче кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

3.8. Координация Советы компетенциясенә ярашлы кабул ителгән карарлар, рекомендация характерына ия.

3.9. Координация советы тарафыннан тикшерелгән иҗтимагый мөһим мәсьәләләр һәм кабул ителгән карарлар җәмәгатьчелек игътибарына массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелә.

3.10. Рәис карары белән, Координация советы утырышына кызыксынган затлар киңәш бирү тавышы хокукы белән чакырыла ала.

3.11. Координация советының эшчәнлеге Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары буенча туктатыла.

Кушымта № 2
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына
_________2017 № ______

Патриотик тәрбия буенча Коодинация советы составы

Самонина Светлана Петровна – Башкарма комитет җитәкчесе, рәис;

Пройдакова Светлана Валерьевна – социаль сораулар буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, рәистәш;

Хисмәтуллин Артур Айрат улы –«Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ начальнигы, рәистәш;

Бурыкина Марина Ивановна –«Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе методисты, секретарь;

Координация советы әгъзалары:

- Нигъмәтуллин Тимур Илдус улы, Форпост” МБУ директоры;

- Рузанов Сергей Александрович, «Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе МББУ директоры;

- Гатиятуллина Алсу Салават кызы, “Атлант” яшүсмерләр-яшьләр клубы МБУ директоры;

- Сәлимгәрәева Аделя Рафаэль кызы, “Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУның баш белгече.

Кушымта №3
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Карарына
_________2017 № ______

Гражданнарны патриотик тәрбияләү буенча чаралар планы

| № | Чара | Сроклары | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| **1. Яшьләрне патриотик тәрбияләү системасын камилләштерү** | | | |
| 1.1. | Призывник көнен уздыру | Ел саен, язгы һәм көзге чакырылыш вакытында | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 1.2. | “Аҗаган” җәйге уеннарын уздыру | Ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ, “Мәгариф бүлеге” |
| 1.3. | Бөек Ватан сугышы ветераннарының яшьләр белән очрашуларын оештыру һәм уздыру | Ел дәвамында | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге”, “Мәгариф бүлеге” МКУ |
| 1.4. | Яшьләрнең Бөек Ватан сугышында Җиңү көнен бәйрәм итүдә катнашулары (бәйрәм митинглары һәм концертлар) | Май аенда, ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге”, “Мәгариф бүлеге” МКУ МКУ «Мәдәният бүлеге” МКУ |
| **2. Россия тарихындагы истәлекле даталарга һәм вакыйгаларга багышланган чаралар оештыру һәм уздыру** | | | |
| 2.1. | Ватанны саклаучылар көне | Февраль ел саен | «Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 2.2. | Гаскәрләрне Әфганстаннан чыгаруга багышланган чаралар | Февраль ел саен | «Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 2.3. | Җиңү көне кысаларында спорт ярышлары | Апрель-май ел саен | “Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ |
| 2.4. | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңү көненә багышланган чаралар | Май ел саен | “Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” “Мәгариф бүлеге» МКУ, «Мәдәният бүлеге” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | МКУ |
| 2.5. | Россия көне | Июнь ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ, МКУ «Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” |
| 2.6. | Хәтер һәм кайгы көне | Июнь ел саен | «Яшьләр эшләре, спөрт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 2.7. | Дәүләт әләме (флагы) көне | Июль ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 2.8. | День республики Татарстан | Август ежегодно | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 2.9. | Халыклар бердәмлеге көне | Ноябрь ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| **3. Яшьләрне патриотик тәрбияләү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү** | | | |
| 3.1. | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында, локаль сугышларда һәм конфликтларда һәлак булган һәм үлгән ветераннарга һәм аларның тол хатыннарына ярдәм итү буенча тимурчылар хәрәкәте | Ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ, Халыкны социаль яклау бүлеге |
| 3.2. | Ү | Май ел саен | «Яшьләр эшләре, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| 3.3. | “Үлемсез полк” акциясендә катнашу | Май ел саен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм” МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Мәдәният бүлеге” МКУ |
| **4. Массакүләм мәгълүмат чараларында патриотизмны пропагандалау** | | | |
| 4.1. | Массакүләм мәгълүмат чараларында патриотик характердагы мәгълүмат урнаштыру | Ел дәвамында | Район массакүләм мәгълүмат чаралары |